**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ивашкино авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Әккәрәй авылы торак пунктында

08 ноябрь 2019 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең Әккәрәй авылы торак пунктында граждannар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең Әккәрәй авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәк граждannардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәяүлеләр күперен ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, суга экспертиза һәм анализ өчен түләү;

- «Әккәрәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ өчен 50 метр койма сатып алу;

- «Ивашкино урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ өчен 30 метрлык керү юлын ремонтлауга төзелеш материаллары сатып алу;

Халык җыенында рәислек итүче
Ивашкино авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Ефимов